| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 02.02.2022 № 77-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы (2018 елның 4 апрелендәге 186-осн номерлы, 2019 елның 3 июнендәге 543-осн номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 624-осн номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә.

Министр Р.Ә. Кузюров